**З. Н. Кириллова**
*Казан федераль университеты (Россия)*

# Югары уку йортларында татар телен укыту (XX гасырның 20-30 нчы еллар тәҗрибәсе)

*Татар теле, дәүләт теле, югары уку йортлары, тел укыту*

1921 елда татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә рус теле белән тигез дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп игълан ителә, һәм аны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә гамәлгә кертү буенча киң эш җәелеп китә [Кириллова, 2000: 169].

Татар телен гамәли яктан тормышка ашыручы ролен Мәгариф комиссариаты үти. Аның карамагындагы төрле тип уку йортларында татар телен укыту һәм татарларны күбрәк җәлеп итү буенча зур эш башкарыла.

20-30 нчы елларда татар телен күпчелек вузларда укыталар, ләкин татарларны кабул итүгә зуррак әһәмият бирәләр. Бу елларда Казанда 5 югары уку йорты исәпләнә. Аларның икесе – элеккеге вузлар: Казан дәүләт университеты – 1804 елдан, ветеринария институты 1874 елдан бирле эшли [За 5 лет, 1925: 112]. Берсе – Көнчыгыш педагогия институты (ВПИ) – 1922 елда элеккеге techninstitут, университетның иҗтимагый фәннәр факультеты һәм Көнчыгыш Академиясе нигезләреннән үсеп чыга [За 5 лет, 1925: 111]. Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты шулай ук 1922 елда университет факультетыннан институт булып аерылып чыга. Совет чоры күренеше һәм яңа нигезләрдә төзелгән Татар коммунистик университеты башка оешма – РСФСР Главполитпросветы карамагында эшли, һәм 1925 елга анда укучы студентларның саны түбәндәгечә билгеләнә: 211 студентның 128е – татар, 54е – рус һәм 29ы – милли азчылыктан. Калган вузлар шулай ук РСФСР карамагында, ләкин аның Главпрофобр идарәсе кул астында эшлиләр һәм үзәктән финансланалар. Татарстан Мәгариф комиссариаты да вузларга кулыннан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша [За 5 лет, 1925: 112]. Ләкин үзәкнең Татарстан югары уку йортларында татар телен гамәлгә кертү өчен акчаны кирәкле күләмдә бирә алмавы, шунлыктан җирле бюджеттан бу максатка җитәрлек кадәр акча бүлеп бирергә кирәк дигән фикер дә мәгариф хезмәткәрләре арасында еш күзәтелә [Доклад, 1927: 42]. Хәтта 1922 елда ук Борындыков Мәгариф комиссариаты хакында ясаган чыгышында вузларны Татарстан Мәгариф комиссариаты карамагына бирергә кирәк дигән мәсьәләне күтәрә, мондый хәл автономияле республиканы канәгатьләндерә алмый, дип күрсәтә. Аның чагыштырулары бик кызык: «Барлык мәгариф эше иң гарип «чукмарбаш» («головастик») формасында күренә, аның башы безнең йогынты астында түгел, ә койрыгы – элементар тәрбия – Татнаркомпрос кул астында. Баш бер юнәлештә хәрәкәт итә, ә койрык болытларга омтыла» [Татарстан, 732, 1, 120: 223].

Турыдан-туры үзәккә буйсынган Казан югары уку йортлары татар студентларын җәлеп итү буенча барлык уку йортлары арасында иң соңгы урыннарда бара. Шулай да элек төп масса татарларга тормышка ашмаслык хыял гына булып күренгән вуз студенты булу бәхете, бик акрынлык белән булса да, елдан-ел күбрәк татарлар өчен чынбарлыкка әверелә бара.

Югары уку йортлары арасында иң аз татар студентлылары булып

ветеринария институты һәм Казан дәүләт университеты санала. Мәсәлән, 1925-1927 елларда ветеринария институтында татарлар 3,7-3,8%ны, ә бу вакытта медицина һәм физика-математика факультетларыннан гына торган университетта 6,7-7,03%ны тәшкил итә [Татарстан, 732, 1, 766: 147]. Гомумән, университетта бу елларда руслар абсолют күпчелекне алып тора.

Агрономнар һәм урманчылар әзерләүче авыл хуҗалыгы институты да Татарстанны гаять кирәкле татар авыл хуҗалыгы белгечләре белән тәэмин итә алмый. Анда укучы татар студентларының саны хәтта милли азчылыктан да азрак була [Татарстан, 732, 1, 769: 14]. 1925-1927 елларда ул 8,4-9,4% арасында тирбәлә. Мәсәлән, 1925 ел ахырына бөтен студентларның саны 960 булып, шуларның 81ен татарлар тәшкил итә. Гомумән алганда, авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты студентларының күпчелеген башка губерна, өлкә һәм республикалардан килгәннәр тәшкил итә, шунлыктан татар телен өйрәнү дә мәҗбүри рәвештә куелмый [Татарстан, 732, 1, 769: 14].

Бары Көнчыгыш педагогия институтында гына татарлаштыру азмы-күпме җайга салына. Исеме үк Көнчыгыш өчен хезмәткәрләр әзерләү икәнне күрсәтеп торган һәм нигездә II баскыч мәктәпләр, эшче факультетлары, техникумнар, крестьян яшьләре һәм ФЗӨ мәктәпләре өчен укытучылар һәм туган якны өйрәнү хезмәткәрләре әзерләүче Көнчыгыш педагогия институтында татарларның бары 12%ны гына тәшкил итүе – зур казаныш түгел, шулай да бары әлеге институтта гына мәҗбүри рәвештә татар теле укытыла [Доклад, 1927: 38], махсус татар бүлеге оештырыла [Третья сессия, 1926: 50]. Дәресләр ике төркемгә бүленеп алып барыла: бер укытучы татар студентлары өчен генә лекция укый, икенчесе – барлык студентлар өчен [Татарстан, 732, 1, 769: 13].

Мәгариф халык комиссары урынбасары Мөхетдиновның 1927 елда булган Татарстан үзәк башкарма комитетының (ТҮБК) 3 нче сессиясендәге чыгышыннан күренгәнчә, Көнчыгыш педагогия институтыннан кала, башка югары уку йортларының берсендә дә татар теле укыту мәҗбүри төстә куелмый [Доклад, 1927: 38]. Ләкин хөкүмәт карарлары нигезендә, мондый хәл килеп чыгарга тиеш булмый, чөнки 1922 елның 8 маендагы ТҮБК карарында югары уку йортларында татар теле укыту кирәклеге билгеләнә [Сборник, 1925: 9], ә шул ук елның 21 декабрендәге инструкциядә инде татар теле өйрәнүнең мәҗбүри икәнлеге ассызыклана [Сборник, 1925: 13]. 1926 елның 25 июнендә Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тарафыннан бирелгән белешмәдә дә урта һәм югары уку йортларында татар теле укытуның мәҗбүри булу фикере кабатлана. Анда күрсәтелгәнчә, студентлар башка предметлар кебек үк, татар теленнән дә зачет бирергә тиешләр, ә зачет бирә алмаганнарга диплом бирелми. Чыгарма булып диплом бирелгән очракта да, дипломга студентның татар теленнән зачет бирмәве языла [Татарстан, 732, 1, 768: 229]. Бары 1925 елның ноябрендә булган Татар телен гамәлгә кую өчле комиссияләре киңәшмәсендә генә барлык вузларның уку планына татар телен факультатив нигезләрдә, ягъни теләгәннәр өчен генә кертү хакында карар кабул ителә [Татарстан, 732, 1, 767: 19]. Шулай итеп, күп санлы карарлар нигезендә, югары уку йортларында татар теле укыту мәҗбүри итеп куелса да, чынлыкта бу мәҗбүрият бары Көнчыгыш педагогия институтында гына тормышка ашырыла, ә башка уку йортларында исә күбесенчә я бөтенләй кертелми, я теләгәннәр өчен генә укытыла.

Югары уку йортларындагы рус студентларына татар теле өйрәтү өчен программа юклык та зур авырлык тудыра. Хәтта 1927 елда да әле вузлар өчен аерым программа төзүне иртәрәк санап, Гыйльми үзәк янындагы методика һәм педагогия комиссиясе әгъзалары II баскыч (9 еллык) рус мәктәпләре өчен төзегән программаларын вакытлы рәвештә югары мәктәпләр өчен дә нигез итеп алырга тәкъдим итәләр. Чөнки, аларның күрсәтүенчә, «югары уку йортлары өчен татар теле – урта типтагы рус мәктәпләренә караганда да яңарак эш. Татар теле кайбер вузларга яңа кергән булса, кайберләренә әлегә кадәр бөтенләй кергәне дә юк. Татар теле укытылган вузларда да эшләр 1 нче курсларда гына түгел, соңгы курсларда да II баскыч рус мәктәпләренең 1 нче, күп булса, 2 нче уку елы өчен программадан, хәтта әлифбадан, югары узганы юк әле» [II баскыч, 1927: 12-13].

Әлеге мәсьәләдән тыш, Татарстан югары уку йортларында татар телен гамәлгә кертүгә аяк чалучы проблемаларның күбесе башка уку йортларындагы белән тәңгәл килә: белемле татар укытучыларының аз булуы, булганнарының да матди кыенлыкта яшәве [Татарстан, 3682, 1, 997: 368], татар теле дәреслекләре, кулланмалары һәм программалары булмау, татар студентларына стипендия аз түләнү [Татарстан, 732, 1, 767: 19], уку йортлары биналарының начар хәлдә булуы, татарлар өчен тулай торак һәм интернатлар кирәк булу [Татарстан, 732, 1, 767: 9] һ. б.

Моннан тыш, Главпрофобр идарәсе үзе дә уку йортларында татар теле укыту мәсьәләсенә җитәрлек әһәмият бирми. Аның үз карамагындагы уку йортларында татар теле атнасына 2 сәгать 2 ел буе укытыла дигән кәгазеннән башка бернәрсә дә булмый [Татарстан, 732, 1, 769: 8].

Документлардан күренгәнчә, 1929-1930 елларда Казан дәүләт университеты студентларына татар телен укытуга да тиешле игътибар бирелеп җиткерелмәгән, аңа университетта икенче дәрәҗәдәге эш итеп кенә каралган. Күренекле галим, 1928-1940 елларда университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире вазифасын башкарган М. Корбангалиев бу караш белән килешә алмаган һәм, татар телен укыту эшенә игътибар иттерү өчен, дирекция каршына үзенең ачык һәм кискен таләпләрен куйган. Мәсәлән, шундый таләпләреннән берсе: “〈...〉 Университетта укучы татар һәм татар булмаган студентларга, каян чыгышларына карамастан, татар телен үтүне мәҗбүри куярга; татар телен белү Татарстан республикасында гына түгел, ә татар-төрек халыклары булган башка республикаларда да эшләргә мөмкинлек тудырачак...” [ИЯЛИ, 43: 20]. Шуңа охшашлы һәм башка таләпләрне М. Корбангалиев берничә мәртәбә куйган һәм шуның нәтиҗәсендә татар телен уку һәм укытуга карашны үзгәрткән. Бу – М. Корбангалиевның татар телен укытуга нинди әһәмият бирүен һәм шуның өчен ничек тырышуын күрсәтә [Вәлеева, 2004: 22-23].

20-30 нчы елларда М. Корбангалиевның үзе генә яки Р. Газиз, Х. Бәдигый, З. Бәдигуллин белән берлектә чыгарган руслар өчен татар теле дәреслекләре зур уңыш казана. Бу дәреслекләргә комплекслылык системасына, табигый һәм тәрҗемәле-грамматика методларына нигезләнү хас.

20 нче елларда татар телен чит тел буларак укытуның яңа эш булуы сәбәпле, бер үк дәреслекләр төрле яшьтәге укучыларны: башлангыч

сыйныфларда, урта мәктәптә, хәтта югары уку йортларында һәм зурлар курсларында укыту максатына хезмәт итәләр, нәтиҗәдә укучыларның яшь үзенчәлекләрен, татар телен белү дәрәҗәләрен исәпкә алып эшләү өчен авырлыклар туа. Бары 30 нчы елларда гына татар телен системалы рәвештә укытуга юнәлдерелгән дәреслекләр барлыкка килә, әмма алар өчен яңа идеология һәм сәясәткә кагылышлы текстларның гаять зур урын алып торуы хас.

М. Корбангалиев техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен 1934 елда “Татарлардан башкалар өчен татар теле дәреслеге”н төзеп бастыра [Корбангалиев, 1934]. Бу дәреслектә морфология һәм синтаксис буенча тулы мәгълүмат бирелә һәм татар әдәбиятыннан да үрнәкләр китерелә. Грамматиканың бүлекләре аерым-аерым бирелгән булса да, материалның һәм күнегүләрнең урыны һәм эчтәлегенә караганда, уку, язу, сөйләм телен үстерү һәм грамматика буенча белем бирүнең бергә бәйләнеп барырга тиешлеге, шулай ук дөрес әйтелешкә дә һәрвакыт игътибар бирү кирәклеге аңлашыла.

Татар теленең күп кенә грамматик формалары, бигрәк тә морфология бүлеге, рус теле белән чагыштырылып бирелә, ягъни М. Корбангалиев, мәктәпләрдәге кебек үк, урта һөнәри һәм югары уку йортларында да рус теле белән татар телен чагыштырма рәвештә өйрәнүне алга куя. Морфологияне өйрәтүгә багышланган бүлек (6-121 б.) синтаксис өлешенә (122-151 б.) караганда күпкә зуррак, аның беренче битләрендә (6-8 б.) шулай ук татар алфавиты, татар теленең авазларын төркемләү, сузык һәм тартык авазларның калын яки нечкә әйтелешенә багышланган, ягъни фонетикага караган материал да урын алган.

Дәреслекнең төзелешеннән күренгәнчә, иң элек татарча текст яки “Сөйләшү” дигән исем белән диалог бирелә, аннан соң рус телендә грамматик нәтиҗәләр чыгарыла, иң соңыннан, үтелгән материалны хәтердә калдыру максаты белән, төрле характердагы күнегүләр урын ала, аларның эчтәлеге сөйләм телен үстерү, язуга өйрәтү һәм грамматик күзәтүләр ясауга юнәлдерелгән. Аерым алганда, рус теленнән татарчага яки киресенчә тәрҗемә итү, төрле фигыль формалары ясау яки төрләндерү, төшереп калдырылган сүзләрне куеп язу кебек эш төрләренә зур урын бирелгән, шулай ук сөйләшү өчен яки сүз төркемнәренең төрләнеше буенча таблицалар һәм схемалар да китерелгән. Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: текстларның бер өлеше көндәлек тормышның гадәти күренешләренә багышланган булса, яңа идеология һәм сәясәткә бәйлеләре күбрәк урынны алып тора. Әдәби материаллар да Ленин һәм Сталинга багышланган текстлар белән башланып китә, шуннан соң гына татар әдипләре хакында кыскача мәгълүмат бирелеп, әсәрләреннән өзекләр китерелә.

Тарихыбызда икенче тапкыр татар теленә дәүләт теле статусы биргән 90 нчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр татар теле күпчелек югары уку йортларының укыту программасына кертелгән, аларда татар бүлекләре яки төркемнәре эшләп килә, укытучылар тарафыннан татар теле дәреслекләре, программалар һәм укыту кулланмалары төзелә. Хисапларда гадәттә урта һөнәри уку йортларында татар телен укыту яки татар төркемнәре булдыру мәсьәләсенең хәл ителмәве ассызыклана. Моннан тыш, хәзерге чор мәгариф системасы буенча түбәндәге кимчелекләрне дә күрсәтергә мөмкин: 1) бүгенге

көндә татар телен гаилә-балалар бакчасы-мәктәп-югары уку йорты һәм хезмәт урыннарында куллану чылбыры бердәм һәм эзлекле рәвештә эшләми, бу компонентлар арасында бәйләнеш һәм үзара хезмәттәшлек итү җитми; 2) югары уку йортларында татар телен укыту яки татарча белем бирү мәсьәләсе хәл ителеп бетмәгән. Вузларда татарча укыту буенча ике тәкъдим бар: студентларны 1-2 курсларда татарча укытып, аннары русчага күчү (Урта Азия республикалары тәҗрибәсе) һәм башта татар телен яхшы итеп өйрәтеп, югары курсларда гына фәннәрне татар телендә укытуга күчү (Балтыйк буе илләре тәҗрибәсе) [Туган телебез, 2004: 5]. Бу ике вариантның кайсы сайлануы әлегә хәл ителмәгән; 3) нинди һөнәр ияләренең татар телен белергә һәм нинди дәрәҗәдә өйрәнергә тиешлеге 20 нче елларда да, хәзер дә анык итеп билгеләнмәгән, ике чорда да "татар халкы белән аралашучы" дигән сүзләр белән генә чикләнәләр. 2004-2013 елларга Дәүләт программасыннан да урындагы затлар һәм дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт телләрен куллану буенча квалификация таләпләре, куллану тармагында дәүләт телләреннән файдалану турында нигезләмәләр эшләү хакындагы пунктның президент таләбе буенча төшереп калдырылуы [Фәйзрахманов, 2004: 6] да бу юнәлештәге эшне туктатты.

Йомгак ясап әйткәндә, XX гасырның 20-30 нчы елларында да, хәзерге вакытта да татар телен югары уку йортларында укыту эше зур авырлыклар һәм каршылыклар белән бара.

## Әдәбият


Вәлеева Ф. С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевның татар телен укыту буенча методик системасы / Ф. С. Вәлеева. – Казан: Мәгариф, 2004. – 143 б.

Доклад Центральной Комиссии по реализации татарского языка при ЦИК Тат. АССР "О положении дела по РТЯ и перспективах" на 3-ей Сессии ЦИКа Татарской АССР 12-13 марта 1927 г. (Стенограмма). Прения и постановление по докладу. – Казань: Изд. ЦК РТЯ при ТЦИК-е, 1927. – 68 с.

За 5 лет. К 5-й годовщине провозглашения ТССР. – Казань: Изд. ТЦИК, 1925. – 208 с.

II баскыч (9 еллык) рус мәктәпләре, шулай ук, вакытлыча, югары мәктәпләр өчен татар теле программасы. – Наркомпрос басмасы, 1927. – 33 б.

ИЯЛИ архивы, 43 ф., 2 тас., 17 эш. – 20 б.

Кириллова З. Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20-30 нчы еллар) / З. Н. Кириллова. – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 208 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен (Техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен) / М. Корбангалиев. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 252 б.

Сборник Декретов, Постановлений, важнейших Циркуляров и других материалов в области реализации татарского языка. – Казань: Изд. Центр. комиссии по реализации татарского языка при ЦИК ТАССР, 1925. – 88 с.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 732 ф., 1 тас., 120 эш. – 522 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 732 ф., 1 тас., 766 эш. – 204 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 732 ф., 1 тас., 767 эш. – 69 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 732 ф., 1 тас., 768 эш. – 297 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 732 ф., 1 тас., 769 эш. – 235 б.

Татарстан Республикасы Милли архивы, 3682 ф., 1 тас., 997 эш. – 907 б.

Третья сессия ЦИК 5-го созыва (с 3-го по 5-е дек. 1925 г.). Стенографический отчет. – Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1926. – 159 с.

Туган телебез, хәлләрең ничек? // Мәдәни җомга. – 2004. – 2 июль.

Фәйзрахманов Ә. Туган тел – иң кадерле тел / Ә. Фәйзрахманов // Мәдәни җомга. – 2004. – 24 сентябрь.